ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail: ik.umr@tatar.ru, sovet.umr@tatar.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_17_»__10_2025 ел №1039

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «Сәлимә Шәмсетдин кызы Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалы тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Түбәндәгене расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе һәм "Сәлимә Шәмсетдин кызы Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее" филиалы тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе (1 нче кушымта);

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «Сәлимә Шәмсетдин кызы Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалының түләүле хезмәтләр прейскуранты (2 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Шәрәфиева Сәлимә Шәмсетдин кызы исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее" муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 06.02.2023 № 129 карарын үз көчен югалткан дип танырга .

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
т. 2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
17.10.2025 ел № 1039

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «Сәлимә Шәмсетдин кызы Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалы тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «Сәлимә Шәмсетдин кызы Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалы тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба - тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, 20.03.2025 «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы № 33-ФЗ , «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре»1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 санлы Россия Федерациясе Законы, «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 санлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясе музей фонды һәм Россия Федерациясе музейлары турында»гы 26.05.1996 № 54-ФЗ Россия Федерациясе Федераль законы, «Россия Федерациясе кинематографиясенә дәүләт ярдәме турында»гы 22.08.1996 № 126-ФЗ Россия Федерациясе Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә театр сәнгатенә дәүләт ярдәме турында»гы 25.03.1999 № 329 карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Мәдәният турында" 03.07.1998 ел, № 1705 Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 14.10.2010 ел, № 69-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиографик һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыру" дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында"гы 2013 елның 17 маендагы 327 санлы карары, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында»гы 08.05.2014 ел, № 397 од

боерыгы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 22.11.2024 № 28 карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 06.07.2023 № 1019 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе уставы һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе директорының 15.08.2023 № 4 боерыгы белән расланган «Сәлимә Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалы турында нигезләмәгә таянып эшләнде.

1.2. Түләүле хезмәтләрне Тәртип нигезендә «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «Сәлимә Шәмсетдин кызы Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалы күрсәтә.

1.3. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

Учреждение - «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе, «Сәлимә Шәмсетдин кызы Шәрәфиева исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалы;

Кулланучы - үзе яки балигъ булмаган гражданнар өчен музей хезмәтләренә заказ бирүче яки сатып алу нияте булган физик яки юридик зат, аларның законлы вәкилләре булып тора, яки хезмәтләрне шәхсән алучы.

1.4. Түләүле хезмәтләр халыкның мәдәният өлкәсендәге ихтыяҗларын һәрьяклап канәгатьләндерү, хезмәтләрне үстерүне һәм камилләштерүне тәэмин итү, учреждениенең матди-техник базасын ныгыту өчен өстәмә финанс чаралары җәлеп итү максатында күрсәтелә.

1.5. Түләүле хезмәтләр күрсәтү учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлегенең бер өлеше булып тора.

1.6. Әлеге тәртип түбәндәгене билгели:

- түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе;
- түләүле хезмәтләргә бәя (тариф) билгеләү тәртибе;
- түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән керемнәрне планлаштыру һәм алардан файдалану тәртибе;
- түләүле хезмәтләрне исәпкә алуны оештыру һәм түләүле хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген контрольдә тоту.

## 2. Түләүле хезмәтләр төрләре

2.1. Учреждение тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр төрләре исемлеге учреждение уставында карала.

2.2. Учреждение Уставта каралмаган хезмәтләр күрсәтергә хокуклы түгел.

## 3. Хезмәтләр күрсәтүне оештыру

3.1. Түләүле хезмәтләр учреждение тарафыннан шартнамә, абонемент, билет яисә хезмәт өчен түләүне раслый торган башка документ нигезендә күрсәтелә, анда номер, түләү суммасы, килү вакыты күрсәтелә.

3.2. Абонемент яки билет формасы Россия Мәдәният министрлыгының «Башкару сәнгате оешмалары һәм музейлар тарафыннан уздырыла торган тамаша чараларына билет, абонемент һәм экскурсия юлламасы формаларын (шул исәптән электрон билет, электрон абонемент һәм электрон экскурсия юлламасы формаларын) катгый хисап бланклары буларак раслау турында»гы 29.06.2020 № 702 боерыгы нигезендә эшләнә һәм учреждение директоры тарафыннан раслана.

3.3. Шартнамәнең яисә 3.1 пунктында күрсәтелгән башка документның формасы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

3.4. Түләүле хезмәтләр күрсәтелгәндә әлеге учреждениенең билгеләнгән эш режимы саклана, бу вакытта түләүсез нигездә күрсәтелә торган хезмәтләр кыскармаска һәм аларның сыйфаты начарланмаска тиеш, шулай ук түләүле хезмәтләр урынына яисә төп устав эшчәнлегенә зыян китереп күрсәтелергә тиеш түгел.

3.5. Учреждение хезмәт күрсәтү вакытын, кулланучыга хезмәт күрсәтү көненә кадәр бер календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр итеп, нигезле сәбәпләр аркасында (үти алмаслык көч шартлары нәтиҗәсендә) күчерергә хокуклы. Хәбәр итү формасы хезмәт күрсәтү кагыйдәләре белән билгеләнә. Хезмәт күрсәтү вакытын күчерүгә риза булмаганда, кулланучыга элек түләнгән, әмма күрсәтелмәгән хезмәтнең бәясе кире кайтарылырга тиеш.

3.6. Учреждение кулланучыларны түләүле хезмәтләр күрсәтү турында түбәндәге күрсәтмә мәгълүмат белән тәэмин итәргә тиеш:

- учреждениенең эш режимы;
- түләүле хезмәтләр күрсәтү графигы;
- түләүле хезмәтләрнең бәясе күрсәтелгән төрләре;
- түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм алу шартлары;
- аерым категория гражданнар өчен ташламалар турында мәгълүмат.

3.7. Күрсәтелгән түләүле хезмәтләр өчен кулланучылар белән исәп-хисаплар контроль-касса техникасын кулланып акчалата да, катгый хисап квитанциясе буенча да, шулай ук билгеләнгән тәртиптә учреждениенең шәхси счетларына акча күчерү юлы белән акчасыз исәп-хисап буенча да башкарыла.

3.8. Учреждение түләүле хезмәтләрне мөстәкыйль рәвештә һәм (яисә) өченче затларны җәлеп итеп (бергә катнашып) Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамә нигезендә күрсәтә ала.

3.9. Түләүле хезмәтләр күрсәткәндә учреждение тарафыннан аерым категория кулланучылар өчен ташламалар бирелергә мөмкин. Ташламалар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә учреждение директоры боерыгы белән билгеләнә.

3.10. Түләүле хезмәтләрне ташламалы шартларда күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат учреждение бинасына килүчеләр өчен мөмкин булган зоналарда һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

## 4. Түләүле хезмәтләргә бәя (тариф) билгеләү тәртибе

4.1. Түләүле хезмәт күрсәтү бәясен (тарифын) исәпләү һәм раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәткән өчен (эшләр башкарган өчен) түләүне билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында»гы 30.12.2010 № 1170 карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Учреждение түләүле хезмәтләргә бәяләрне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты белән килештереп раслый.

## 5. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрне планлаштыру һәм алардан файдалану тәртибе

5.1. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрне планлаштыру түләүле хезмәтнең һәр конкрет төре буенча учреждение эшчәнлегенең сан күрсәткечләре нигезендә, шулай ук тәртипнең 4.1 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Учреждение ел саен норматив хокукый актларда билгеләнгән срокларда бюджет классификациясе кодлары киселешендә чираттагы финанс елына түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр килү фаразын төзи һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыра.

5.3. Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән алынган керемнәр, хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне дә кертеп, кимендә 50% күләмендә хезмәт өчен түләүгә һәм учреждение хезмәткәрләрен кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелә.

## 6. Түләүле хезмәтләрне исәпкә алуны оештыру һәм түләүле хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген тикшереп тору

6.1. Учреждение түләүле хезмәтләрнең бухгалтерлык, салым һәм статистик исәбен билгеләнгән тәртиптә алып бара.

6.2. Түләүле хезмәтләр күрсәтү буенча учреждение эшчәнлеген тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Учреждение эшчәнлеген законнар нигезендә тикшереп тору һәм күзәтчелек итү функцияләрен башкаручы башка органнар гамәлгә ашыра.

6.3. Түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм түләүле хезмәтләрдән керемнәрне исәпкә алу буенча Учреждение эшчәнлеген оештыру өчен учреждение директоры җаваплы.

## 7. Түләүле хезмәтләр күрсәткәндә ташламалар

7.1. Учреждениенең түләүле чарасына кергән өчен түләү буенча ташлама ташламага хокук бирә торган документлар бирелгәндә түләү күләмен киметү юлы белән акчасыз бирелә.

7.2. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә учреждениегә түләүсез керү хокукы бирелде:

- айның һәр беренче сишәмбесе - барлык категория гражданнар өчен экскурсия хезмәтеннән башка түләүсез керү көне;
- Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына, Дан орденының тулы кавалерларына (таныклык күрсәткәндә);
- ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (мәктәп җитәкчелегеннән мөнәсәбәт күрсәтелгәндә);
- унсигез яшькә җитмәгән кешеләргә - айга бер көн (һәр айның соңгы җомгасы);
- студентларга - айга бер тапкыр (һәр айның соңгы җомгасы);
- күпбалалы гаиләләргә - айга бер көн (күпбалалы гаилә таныклыгына кертем күрсәтелгәндә);
- мәктәпкәчә яшьтәге балаларга;
- экскурсия төркемнәрен озатып йөрүче җитәкчеләргә экскурсия юлламасы булганда;
- учреждениегә түләүсез керү өчен учреждение тарафыннан бирелгән сертификат булганда;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт музейлары хезмәткәрләренә (тиешле таныклыкны күрсәткәндә).
- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре Татарстан Республикасы буенча эшләр, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләре (гаилә әгъзалары)

7.2. Учреждениедә халыкның түбәндәге категорияләре өчен ташламалар билгеләнгән: (билет бәясенең 50% ы):

- инвалидлар өчен (таныклык күрсәткәндә);
- вакытлы хезмәт солдатлары өчен (хәрби часть җитәкчелегеннән таныклык яисә мөнәсәбәтләр күрсәткәндә);
- локаль хәрби конфликтлар ветераннары өчен (таныклык күрсәткәндә):
- пенсионерлар өчен (пенсия таныклыгын күрсәткәндә).

7.3. Түләүсез һәм ташламалы керү хокукы килүчене ташламалы категориягә кертүне таныклаучы тиешле документ (таныклык, юллама бирүче оешманың мөнәсәбәте һ.б.) бирелгәндә генә барлыкка килә.

7.4. Әлеге ташламалар учреждениегә килүчеләрнең башка категорияләренә кагылмый, физик яки юридик зат булсынмы.

5.4. Юридик затларга музейда билгеләнгән тарифлар буенча хезмәт күрсәтелә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
17.10.2025 ел № 1039

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы тарих-туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесенең һәм «Шәрәфиева Сәлимә Шәмсетдин кызы исемендәге Кәрәкәшле туган якны өйрәнү музее» филиалының түләүле хезмәтләр прейскуранты

| Хезмәтләр исеме | Бәясе, сумнарда |
|---|---|
| Музейның экспозиция залларына экскурсия хезмәтеннән башка бару | |
| өлкәннәр өчен | 100 |
| 14 яшькә кадәрге балалар өчен | 50 |
| Пушкин картасы буенча | 100 |
| Экскурсия хезмәте күрсәтелә торган экспозиция залларына бару | |
| өлкәннәр өчен | 150 |
| 14 яшькә кадәрге балалар өчен | 100 |
| Пушкин картасы буенча | 150 |
| Фонд саклагыч хезмәтләре | |
| консультацияләр | 100 |
| мәгълүмат бирү | 100 |
| Музейның басма продукциясе | |
| А4 форматындагы календарьлар һәм фотографияләр | 100 |
| кесә календарьлары | 50 |
| открыткалар | 50 |
| брошюралар | 150 |
| сувенирлар | 100-500 |
| Интерактив җайланмалар кулланып экскурсия | |
| өлкәннәр өчен | 200 |
| 14 яшькә кадәрге балалар өчен | 100 |
| Пушкин картасы буенча | 200 |
| Башка хезмәтләр | |
| өлкәннәр өчен мастер-класс | 250 |
| 14 яшькә кадәрге балалар өчен мастер-класс | 200 |
| Пушкин картасы буенча мастер-класс | 350-450 |
| үз фотоаппараты белән экспозицияләрне фотога төшерү хокукы өчен | 50 |
| архив материалларын, китапларны, документларны күчереп алу 1 бит (А-4) | 5 |